ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.03.2022 Олы Кайбыч ав. № 130

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 июлендәге 293 номерлы карары белән расланган индивидуаль торак төзелеше объекты яисә бакча йорты параметрларын планлаштырылган төзү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының билгеләнгән параметрларына һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яисә җир кишәрлегендә урнаштыру мөмкинлеге хакында хәбәр итү юнәлеше буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 декабрендәге 476-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Индивидуаль торак төзелеше объекты яисә бакча йорты параметрларын планлаштырылган төзү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының билгеләнгән параметрларына һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яисә җир кишәрлегендә урнаштыру мөмкинлеге хакында хәбәр итү юнәлеше буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.5.1 пунктының беренче абзацында «индивидуаль торак төзелеше объектын төзүдә яисә реконструкцияләүдә» сүзләрен «индивидуаль торак төзелеше объектын төзүдә, реконструкцияләүдә» сүзләренә алмаштырырга (индивидуаль торак төзелеше объектларын «күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп алып төзүдән тыш).».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А. Н. Макаров